РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ ИЛЯКСАЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
Село Иляксаз, улица Комсомольская дом 2, 423356 Телефон 4-70-22

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИЛЕКСАЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
Комсомол урамы,2 йорт, Илексаз авылы,423356
Телефон: 4-70-22

ОГРН 1021601313183 ИНН/КПП 1636001354/163601001 ОКАТО 92253820000

РЕШЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР
20.09.2019 ел　　　　　　　　　　　　　　　　　　№ 16

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел, № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» гы Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 22, 56 статьясы, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы Законының 20 статьясы 1 пункты, Илексаз авыл җирлеге Уставы, Сарман муниципаль районы Илексаз авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне башлап җибәрергә: "2020 елда Илексаз авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча I группа инвалидларыннан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш теркәлгән һәр балигъ булмаган кешедән 200 сум күләмендә үзара салым акчаларын, һәм алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү белән килешәсезме?:

- юл корылмаларын буяу өчен буяулар сатып алу, юл тамгасы төшерү;
- Илексаз авылы Октябрьнең 70 еллыгы урамы, юлларга вак таш җәю (вак таш ташу) ;
- Илексаз, Мортыш Баш, Игәнә-Баш авылларында массакүләм чаралар (Сабантуй, юбилярлар) үткәрү өчен бүләкләр сатып алу ;
- «Беларус 82.1» тракторын карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, һәм машина йөртүчегә хезмәт күрсәтү өчен түләү);
- Илексаз авылында мәктәп автобусын туктату өчен павильон сатып алу;
-Мортыш Баш авылындагы " Сабантуй» мәйданын төзекләндерү өчен төзелеш материаллары сатып алу (өй тышлыгы, эскәмияләр буяу);
- Илексаз, Игәнәбаш, Мортыш Баш авыллары урам яктырткычлары сатып алу;

ӘЙЕ　　　　　　　　　　　　　　　　　　　ЮК?».

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Илексаз авыл җирлеге Советы рәисе:　　　　　　　Ф.М.Гыйлфанов